КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 170

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 нче пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

14 – 16 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппаратына мәҗбүри ачык хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыруга җибәрергә.

15. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мәҗбүри ачык хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

16. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет

учреждениесенә оешмалар тарафыннан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәя бирүне оештыру эшчәнлеген оештыру-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.»;

түбәндәге эчтәлекле 17 нче һәм 18 нче пунктлар өстәргә:

«17. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

оешмалар тарафыннан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәя бирүне гамәлгә ашыру буенча шундый ук карарлар кабул итәргә;

ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленә кадәр, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, мәҗбүри ачык хисапны формалаштыру өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хисап кертергә.

18. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин